Республика Татарстан
Сармановский
муниципальный район
Исполнительный комитет
Азалаковского сельского поселения
423371 с. Азалаково ул Зеленая дом 8В
Телефон ( 85559) 4 – 80 – 36

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге
Башкарма комитеты
423371 Азалак авылы Яшеллек урамы
8В йорты.

ОГРН 1061687002552, ОКПО 93068255, ОКАТО 92253804000,
ИНН/ КПП 1636005479/163601001, ОКТМО 93653404

Постановление
№ 8

Карар
14.06.2024 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге башкарма комитетының бухгалтеры хезмәте өчен түләү шартлары турында

Сарман муниципаль районының Азалак авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге башкарма комитетының бухгалтеры хезмәте өчен түләү шартлары турында» нигезләмәне расларга.

2. Азалак авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Азалак авыл җирлеге белгеченең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 26 апрелендәге 7 номерлы карарын гамәлгә яраксыз дип санарга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә игълан итәргә.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Г.Габдулгазизов

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Азалак авыл җирлеге башкарма комитеты карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге башкарма комитетының бухгалтеры хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге башкарма комитетының бухгалтеры хезмәтенә түләү шартларын билгели, аларга Татарстан Республикасы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый.

2. Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтерының хезмәт хакы айлык хезмәт хакыннан, тиешле еллар эшләгән өчен айлык хезмәт хакына айлык өстәмә түләүдән, эш интенсивлыгы өчен айлык түләүдән, айлык акчалата бүләкләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, акчалата бүләкләүдән, акчалата ярдәмнән, матди ярдәмнән һәм еллык түләүле отпускны биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән тора.

3. Бухгалтерның вазыйфаи окладым түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфасы | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 меңнән артык кеше |
| Бухгалтер | 21 900 сум | 22 500 сум |

4. Бухгалтерга түбәндәгеләр билгеләнә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен түбәндәге күләмнәрдә өстәмә:

| Эш стажы | Айлык өстәмәләр, процентлар |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү;

3) вазыйфаи окладның 37 проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

4) еллык түләүле отпуск биргәндә вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләү.

Календарь ел дәвамында бухгалтерга еллык түләүле отпуск бирелмәгән очракта, бер тапкыр түләнә торган түләү, эштән чыгарылган очракта - соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, декабрьдә башкарылган вакытка пропорциональ рәвештә түләнә.

Еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләү беренче елда календарь елда башкарылган чорга пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы календарь елның 31 декабре буенча эшкә кергән көннән исәпләнә.

5) хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә матди ярдәм;

6) эш нәтиҗәләре буенча премия.

5. Бухгалтерның еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$\boldsymbol{FOT} = \sum_{i}^{\boldsymbol{n}}((0_d + 0,3 * \boldsymbol{O_d}) * \boldsymbol{к}) * (1 + г) + \sum_{i}^{\boldsymbol{n}} P * (1 + г);$$

биредә:

РОТ - бухгалтерларның еллык хезмәт хакы фонды;

0а - бухгалтерга хезмәт хакын түләүгә акча суммасы;

0,3 * $\boldsymbol{O_й}$- тиешле елларны эшләгән өчен айлык хезмәт хакына айлык өстәмә түләүгә, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпускны биргәндә бер тапкыр түләнә торган акчалата түләү, матди ярдәм өчен айлык вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүгә акчалар суммасы;

Р - бухгалтерларның еллык премия фонды;

***n*** -бухгалтерларның штат саны;

***к*** - 12 ай;

С- хезмәт өчен түләү буенча түләүләр.